Татарстан Республикасы

Актаныш муниципаль районы Богады төп гомуми белем бирү мәктәбе

***Иҗади-эзләнү проекты***

# ТЕМА: ТӨРЛЕ ИЛЛӘРДӘГЕ ЯҢА ЕЛ СИМВОЛЛАРЫ ҺӘМ ТРАДИЦИЯЛӘРЕ






**Иҗади-эзләнү проектында Богады төп гомуми белем бирү мәктәбенең 2 нче сыйныф укучылары катнашты.**



**Чыгышны әзерләделәр:**

**Нуриев Гадел**

**Арсланова Энҗе**

# МАКСАТ:

1. Россиядә һәм башка илләрдәге Яңа ел бәйрәме символлары һәм традицияләре турында өйрәнү.
2. Барлык халыкларның традицияләренә карата кызыксыну һәм хөрмәт тәрбияләү.
3. Халык алдында чыгыш ясау һәм үз позициянңне саклый белүгә күнектерү.

# КӨТЕЛГӘН НӘТИҖӘ:

**ЯҢА ЕЛНЫ БӘЙРӘМ ИТКӘНДӘ БӨТЕНДӨНЬЯ ХАЛКЫН ОХШАШ СИМВОЛЛАР ҺӘМ ТРАДИЦИЯЛӘР БЕРЛӘШТЕРӘ.**





# Эзләнү-тикшеренү этаплары



# Тарихчылар  ни сөйли?

**Борынгы Русьта яңа ел март аеннан башланган.  Аны яз, кояш һәм жылылык бәйрәме буларак каршылаганнар.**






**Русьта христианлык кабул ителгәннән соң, X гасырдан башлап, яңа елны 1 сентябрьда каршы ала башлыйлар.**



1699 елда Русь патшасы Петр 1 Яңа елны 1 январьда бәйрәм итү турында Указ чыгара.

1699 елда Петр I беренче тапкыр һавага ракета җибәрә. Елан формасында сузылган солют утлары 1 январь көнне Яңа ел башлануын хәбәр итә.





Шул вакыттан башлап Яңа ел бәйрәмен бөтен дөньяда киң колач белән үткәрәләр.

# ГЕОГРАФЛАР

## Яңа елга кем хуҗа?



# Дед Мороз



**Элекке заманнарда Русьта аны төрлечә атаганнар: Дед Трескун, Мороз Ёлкич, Студенец, Дед Мороз, Морозко, Мороз Красный нос, Мороз Иванович.**

**Ә татарлар аны яратып: Кыш бабай, Суык бабай, Кар бабай дип йөртәләр.**



Кагыйдә буларак, ул җәяү яки чаңгы белән хәрәкәт итә.

Ерак араларны ак атлар җигелгән тройкада үтә.

Элекке заманда, Кыш бабай яшьрәк, куәтлерәк чагында, балаларга һәм зурларга бүләк өләшеп кенә калмаган, ә ачуын китергәннәрнең йорт-җирләрен дә туздырып киткән.



Хәзер ул күпкә мәрхәмәтлерәк, Яңа ел алдыннан кунак булып килә һәм бүләк-күчтәнәчләр өләшә. Дөрес, бүләк өләшүче аңа җырларга яки шигырь сөйләргә тиеш була.

1998 нче елда Кыш Бабайның Россиядәге Ватаны итеп Великий Устюг аталды.





Аңа түбәндәге адрес буенча хат язарга була: 162340 Россия, Вологодская обл., г. Великий Устюг. Деду Морозу.

# Кыш бабайның башка илләрдәге коллегалары





# Бөекбритания һәм Америкада

## САНТА КЛАУС





# ДАНИЯ



Даниядә ике Кыш бабай икән: Юлеманден һәм Юлениссе.Бу бабайлар Гренландиядә мәңгелек бозлык арасында яшиләр. Юлеманден – өлкән бабай.Аның ярдәмчеләре бар.Эльфлар. Ә Юлениссе – кече Кыш бабай урманда яши һәм төлкеләр җигелгән чанада йөри.



# ИТАЛИЯ



Италиядә тыңлаучан балалар янына ягымлы Фея Бефана килә. Ул төтен суыргычтан очып керәп аларга бүләкләр калдыра. Шук балаларга тылсымлы Бефанадан күмер эләгә.



**Пер – Ноэль киң кырлы эшләпә кия.Аның кәрзинендә балаларга бүләкләр була.Ә тыңлаусыз һәм ялкау балалар өчен кәрзин төбенә чыбыркы яшерелгән.**

# ҮЗБӘКСТАН

Үзбәк кышлагына ишәккә атланган, буй-буйлы халат кигән Кар бабай «Корбобо» килә.



# Ә бу безнең  Кар бабай!



# Швеция



**Швециядә кешеләр бер-берсенә үзләре ясаган шәм бүләк итәләр. Ә әтиләр Яңа елны каршылар алдыннан чүп чиләге түгәргә чыгалар.**



# Финляндия



**Финнарның Яңа ел табынында слива киселе һәм дөге боткасы була.**





Германиянең борынгы халыклары чыршыда урман җаны(дух) яши һәм ул үсемлекләрне, җәнлекләрне,кошларны саклый дип ышанганнар. Бу бөек җанга алар табынганнар, хөрмәт йөзеннән өйгә алып кайтканнар, аңа үзләре ясаган уенчыклар, бүләкләр элгәннәр.



Голландиялеләр һәм инглизләр чыршы агачын мәңгелек яшьлек символы итеп саныганнар.

Россиядә Яңа ел Чыршысы Петр 1 тарафыннан кертелгән. Ул 1700 елның 1 нче январен каршы алганда барлык өйләрне дә чыршы яки нарат ботаклары белән бизәргә боерган. Үрнәк итеп Гостиный Двордагы чыршы ботагы күрсәтелгән.



# Чыршыны уенчыклар, тәм-томнар белән бизиләр











# Гаждәеп чыршылар










# Яңа ел РЕКОРДЛАРЫ



Бу ясалма чыршыга 120 яшь



Иң биек чыршы
46 м
Мәскәү, 2014 ел.

# Художниклар

Яңа ел открыткалары нәрсә турында сөйли?







Беренче Яңа ел открыткасы Лондонда барлыкка килгән.

Почта аша аны **1843** нче елда Генри Коул җибәргән.














Яңа ел открыткалары узып баручы елның иң истәлекле вакыйгаларына багышланган. Без шундыйлардан Бөек Җиңүгә һәм Космоска очу вакыйгасына бәйле открыткалар очрадык.

# Күзәтүләр нәтиҗәсе:

- 1699 нчы елдан башлап Яңа ел бәйрәмен бөтен дөньяда киң колач белән үткәрәләр.
- Күпчелек илләрдә дә Яңа елның хуҗасы бар.Ул-Кыш бабай һәм аның коллегалары.
- Күпчелек илләрдә дә Яңа елның төп бизәге-Чыршы, уенчыклар, кучтәнәчләр, бүләкләр.
- Котлау открыткалары җибәрү барлык халыкларның да яраткан шөгыле булган.

**Күзәтүләребез көтелгән нәтиҗәне раслыйлар.Чыннан да, Яңа елны бәйрәм иткәндә Бөтендөнья халкын охшаш символлар һәм традицияләр берләштерә.**

# Игътибарыгыз өчен рәхмәт!





**Җитәкче: Салихова Г.Г.**
**Богады төп гомуми белем бирү мәктәбенең башлангыч сыйныфлар укытучысы**